

Үзара салым (Программа самообложения) программасы республикада кин таралган. Халык жыйган һәр 1 сумга Мордовия бюджеты vзенен 4 сумын да ости. Халыкнын акчалары турыдан-туры конкрет эшләргә китә һәм һәркем аларнын нәрсәгә тотылганын кvзәтә ала.
Темников районы Тархан авылы халкы 2022 елнын октябрендә урамнарны яктырту мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын vткәреп һәр балигъ булган кешедән 1000 сум жыйган иде. Жавап биргән һәм vз олешләрен керткән кешеләргә зур рәхмәт әйтә бу эшне башкаручылар. Әмма яктырту идеясен хупламаган кешеләр дә булган ул вакытта. Светодиодлы яктырткычлар урнаштыру буенча эшләр тулы куәтенә алып барыла.
2023 елнын 03 ноябрендә граждан-нарнын кабат жыелышы узган һәм анда акча жыюны дәвам итәргә карар ителгән. Шулай ук Аксель авыл жирлеге депутаты Кугушева Халисә Сафиулла кызы балалар уен мәйданчыгы тозелешенә, vзара салым программасы буенча, акча жыюны башларга тәкъдим иткән. Һәр хужалыктан 3000 сум жыярга дигән бертавыштан карар кабул да ителгән. Тархан авылында туып-vскән яшьләргә, шәһәрләрдә яшәvчеләргә, балалар мәйданчыгы тулырак булсын һәм балаларга шатлык китерсен очен, әлеге инициативаны хупларга һәм момкин кадәр матди ярдәм кvрсәтергә морәжәгать итәләр: Сезнен анлавыгызга һәм катнашуыгызга ометләнәбез!
Сезнен һәрберегез vз жаныгызнын бер олешен авылны тозекләндерvгә сала ала һәм шунын белән vз Ватаныбызга булган мәхәббәтебезне кvрсәтербез һәм авылыбызны бераз матуррак итәрбез.

*Фото һәм мәгълумат Тархан социаль челтәреннән*